КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.07.2024 № 340-П

Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Түбән Үрәс авылы, Мәктәп урамы 1 нче йорт адресы буенча эзләп табылган «Мәчет», 1907 ел мәдәни мирас объектын, төбәк өчен әһәмиятле «Мәчет», 1907 ел мәдәни объект сыйфатында, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) бердәм дәүләт реестрына кертү, мәдәни мирас объектын саклау, чикләрен билгеләү һәм аннан файдалану режимын раслау турында

2002 нче елның 25 нче июнендә гамәлгә кергән 73-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләр) турында»гы Федераль законы, 2005 нче елның 1 нче апрелендә гамәлгә кергән 60-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында»гы Татарстан Республикасы Законы, дәүләт тарихи-мәдәни экспертизасының 2024 елның 15 нче июненә караган уңай бәяләмәсенә нигезләнеп боерам:

1. Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Түбән Үрәс авылы, Мәктәп урамы 1 нче йорт адресы буенча эзләп табылган «Мәчет», 1907 ел мәдәни мирас объектын, төбәк өчен әһәмиятле «Мәчет», 1907 ел мәдәни объект сыйфатында, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) бердәм дәүләт реестрына кертергә.

2. Әлеге боерыкка караган 1 нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Түбән Русь авылы, Мәктәп урамы, 1 нче йорт адресы буенча урнашкан «Мәчет» региональ әһәмияттәге

мәдәни мирас объекты территориясе чикләрен расларга.

3. Әлеге боерыкка караган 2 нче кушымта нигезендә, Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Түбән Русь авылы, Мәктәп урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан региональ әһәмияттәге «Мәчет» мәдәни мирас объектының сак предметын расларга.

4. Мәдәни мирас объектларын һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеген исәпкә алу бүлегенә, күрсәтелгән мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында белешмәләрне, күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына һәм Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.

5. Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы Мәдәни
мирас объектларын саклау
комитетының 2024 елның 12
июльдәге 340-П номерлы
боерыгына караган 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Түбән Үрәс авылы, Мәктәп урамы 1 нче йорт адресы буенча урнашкан «Мәчет», 1907 ел. төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объектының

**территориясе чикләре**

Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Түбән Үрәс авылы, Мәктәп урамы 1 нче йорт адресы буенча урнашкан «Мәчет», 1907 ел. төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объектының
территория чикләре картасы (схемасы)




Масштаб 1:500

Шартлы билгеләр:

| | |
|---|---|
| | - мәдәни мирас объекты территориясе чикләре |
| 1● | - мәдәни мирас объекты территориясе чикләренең характерлы ноктасы |
| | - мәдәни мирас объекты |
| | - мәдәни мирас объекты территориясе |
| 337 | - җир кишәрлегенең кадастр номеры билгесе |

Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Түбән Үрәс авылы, Мәктәп урамы 1 нче йорт адресы буенча урнашкан «Мәчет», 1907 ел. төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объектының
текст рәвешендәге тасвирланмасы

Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Түбән Үрәс авылы, Мәктәп урамы 1 нче йорт адресы буенча урнашкан «Мәчет», 1907 ел. төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объектының
территорияе чикләре түбәндәге урыннардан уза:

| Чикне узу | | Чикне узуның тасвирламасы |
|---|---|---|
| ноктадан | ноктага кадәр | |
| 1 | 2 | 1 нче ноктадан төньяк-көнчыгыш юнәлештә мәктәп урамы буйлап 2 нче ноктага кадәр; |
| 2 | 3 | Мәктәп урамы киселешендә урнашкан 2 нче ноктадан алып, көньяк-көнчыгыш юнәлештә Ушман елгасына параллель рәвештә 3 нче ноктага кадәр; |
| 3 | 4 | 3 нче ноктадан башлап, көньяк-көнбатыш юнәлештә, кадастр номеры 16:23:210601:337 булган җир кишәрлеге чиге буйлап, 4 нче ноктага кадәр |
| 4 | 1 | 4 нче ноктадан башлап, төньяк-көнбатыш юнәлештә, кадастр номеры 16:23:210601:337 булган җир кишәрлеге чиге буйлап, Мәктәп урамы юнәлешендә 1 нче ноктага кадәр. |

Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Түбән Үрәс авылы, Мәктәп урамы 1 нче йорт адресы буенча урнашкан «Мәчет», 1907 ел. төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объектының территориясе чикләренең характерлы нокталары таблицасы

| № | Җирле координаталар системасындагы характерлы нокталарның координаталары (МСК-16) | |
|---|---|---|
| | X | Y |
| 0. | 500990.70 | 2234398.43 |
| 1. | 500971.92 | 2234432.85 |
| 2. | 500924.32 | 2234403.44 |
| 3. | 500942.24 | 2234370.49 |
| 1 | 500990.70 | 2234398.43 |

Татарстан Республикасы
Мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының 2024
елның 12 июльдәге 340-П
номерлы боерыгына караган 2
нче кушымта

Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Түбән Үрәс авылы, Мәктәп урамы 1 нче йорт адресы буенча урнашкан «Мәчет», 1907 ел. төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объектының
**сак предметы***

1. Бинаның урыны авыл читендәге ачык калку җирдә, Ушман елгасы яры буенда, Мәктәп урамындагы төзелешкә почмаклап тора.

2. Шәһәр төзелешендәге доминантларның (чын манара югалган) характеристикалары, авыл төзелеш силуэтын актив формалаштыра.

3. Төньяктан көньякка сузылган бер катлы таш бинаның беренчел күләм-киңлек структурасы, түбә үзәгендә манаралы бүлмәсе булган мәчетләр тибына керә: туры почмаклы киңлек, үз эченә көнбатыш һәм көнчыгыш фасадына чыга торган, өч тәрәзә уемы булган, намаз уку залы рәвешендәге мөнбәрле өлешне, ике тәрәзә уемлы керү өлешен берләштерә. Керү төньяк фасадтагы зур булмаган туры почмаклы өйалды (югалтылган) аша оештырылган. Көньяк фасад үзәге буйлап, ярымтүгәрәк михраб, түбә үзәгенә корылган алты кырлы каркас тибындагы манара (югалтылган) урнашкан.

4. Беренчел күләм-планлаштыру анфилад карары нигезендә стандарт схема буенча үзәк планировкалы, төрле зурлыктагы өч бүлмәдән тора торган, зал мәчете (өйалды-керү өлеше-намаз уку залы): ишеккә терәп төзелгән, зур булмаган туры почмак формасындагы өйалды (югалтылган), турыпочмаклы барсыннан да зуррак, көньяк диварында михраб уентыгы булган намаз уку бүлмәсеннән; күчәр уемлы аркылы дивар белән бүленгән, бинаның төп мәйданынан кечерәк булган мәйданны тәшкил итүче керү өлешеннән (югалтылган, фундаментның калдыклары сакланган).

5. Конструктив схемасы: элеккегедән сакланган, кыргый бутовой таш стеналар; агач балкаларга салынган яссы такта түшәмәләр; уемнарда аркылы агач тыгылышлар; агач тәрәзә төпләре; керү юлының уң ягында сакланган таш нигезгә төзелгән, чормага алып бара торган ике маршлы агач баскыч (югалтылган); манараның урнашу урыны, конфигурациясе, габаритлары, конструкциясе, манараның һәм манараның ахырына кадәр тәмамлану материалы (югалтылган)

6. Мәчетнең төп өлешен тәшкил иткән, дүрт яклы вальма түбәнең, ике яклы михраб түбәсенең һәм түбәнең югары нокталарыннан түбәнрәк урнашкан агач өйалды түбәсенең тарихи конфигурация һәм габаритлары (беренчел сыйфатта югалтылган); алты кырлы нигездә урнашкан, киселешендә күпкырлы, чатыр рәвешендә тәмамланучы (югалтылган) манараның тарихи конфигурация һәм габаритлары; түбәнең тарихи

материалы: табаклы тимер.

7. Фасадларның композицион һәм архитектур бирелеше: биш тәрәзә күчәрендәге, диварлар яссылыгыннан чыгып торган вертикаль буынлы, почмаклы һәм стена ара пилястралы бинаның төп өлешенең көнбатыш һәм көнчыгыш фасадларының ике өлешле композициясе – намаз уку бүлмәсенең өч тәрәзә күчәре белән аерылып чыгарылган өлеше, ике тәрәзә күчәре белән аерылып чыгарылган вестибюльнең бер өлеше, көньяк диварның уртасында урнашкан, бинаның биеклеге белән тәңгәл михрабның тәрәзә белән яктыртылган ярымцилиндрлы киңлеге.

8. Тарихи тәрәзә һәм ишек уемнарының урнашу урыны, конфигурациясе һәм пропорцияләре; тәрәзә һәм ишек уемнарының колодалы столярлык тутырылышының геометриясе һәм конструкциясе (тутырулар юкка чыккан).


9. Фасадларның бизәлеше һәм архитектура детальләре: бинаның таш фасадлары өслеге известь сылау буенча буялган, көнбатыш һәм көнчыгыш фасадларның урта өлешендә почмакларны эшкәрткәндә һәм тәрәзә уемнарында яссы профильле пилястрлар, яссы йөзлекләр белән рамланган турыпочмаклы тәрәзә уемнары баскычлы профильле кәрниз рәвешендә тәмамланган.

10. Интерьерларның декоратив бизәлеше: штукатурланган һәм буялган шома диварлар (буяу катламнары зондаж ачулар һәм химик-технологик тикшеренүләр нәтиҗәләренә таянып билгеләнә), михрабның гипс белән рамланган аркалы куышы (югалтылган); таш баганаларга салынган агач балкалар буенча җәелгән такта идәннәр (югалтылган); агач түшәм түбә өрлекләренә салынган, таш стена ояларына ябыштырылган такталар.


* Сак предметы объектны комплекслы тикшергәндә, шулай ук реставрация эшләрен башкару процессында төгәлләштерелергә һәм өстәмәлмәләр кертелергә тиеш.

Татарстан Республикасы, Кукмара муниципаль районы, Түбән Үрәс авылы, Мәктәп  урамы 1 нче йорт адресы буенча урнашкан «Мәчет», 1907 ел. төбәк өчен әһәмиятле мәдәни мирас объектының
сак предметы таблицасы

| № | Сак предметы | Төп элементларны фотофиксацияләү/график материаллар |
|---|---|---|
| 1 | Бинаның урыны авыл читендәге ачык калку җирдә, Ушман елгасы яры буенда, Мәктәп урамындагы төзелешкә почмаклап тора. |   Рәсем. 1. Объектның урнашу урыны |
| 2 | Шәһәр төзелешендәге доминантларның (чын манара югалган) характеристикалары, авыл төзелеш силуэтын актив формалаштыра |  Рәсем. 2. Көнчыгыштан гомуми күренеш |

| | | |
|---|---|---|
| | | <br>Рәсем. 3. Төньяк-көнчыгыштан гомуми күренеш |
| 3 | Төньяктан көньякка сузылган бер катлы таш бинаның беренчел күләм-киңлек структурасы, түбә үзәгендә манаралы бүлмәсе булган мәчетләр тибына керә: туры почмаклы киңлек, үз эченә көнбатыш һәм көнчыгыш фасадына чыга торган, өч тәрәзә уемы булган, намаз уку залы рәвешендәге мөнбәрле өлешне, ике тәрәзә уемлы керү өлешен берләштерә. Керү төньяк фасадтагы зур булмаган туры почмаклы өйалды (югалтылган) аша оештырылган. Көньяк фасад үзәге буйлап, ярымтүгәрәк михраб, түбә үзәгенә корылган | <br><br>Рәсем. 4. Түбән Үрәс авылында мәчет төзү өчен архив проекты, 1907 ел |

<table>
<tr>
<td></td>
<td>алты кырлы каркас тибындагы манара (югалтылган) урнашкан.</td>
<td>




Рәсем. 5. Түбән Үрәс авылында мәчет төзү өчен архив проекты, 1907 ел



Рәсем. 6. Михраб күренеше

</td>
</tr>
</table>


| | | |
|---|---|---|
| 4. | Беренчел күләм-планлаштыру анфилад карары нигезендә стандарт схема буенча үзәк планировкалы, төрле зурлыктагы өч бүлмәдән тора торган, зал мәчете (өйалды-керү өлеше-намаз уку залы): ишеккә терәп төзелгән, зур булмаган туры почмак формасындагы өйалды (югалтылган), турыпочмаклы барсыннан да зуррак, көньяк диварында михраб уентыгы булган намаз уку бүлмәсеннән; күчәр уемлы аркылы дивар белән бүленгән, бинаның төп мәйданынан кечерәк булган мәйданны тәшкил итүче керү өлешеннән (югалтылган, фундаментның калдыклары сакланган) | <br>Рәсем. 7. Көньяктан төньякка булган юнәлештәге күчәр буенча мәчет киңлегенең гомуми күренеше<br><br>Рәсем. 8. Төньяктан көньякка булган юнәлештәге күчәр буенча мәчет киңлегенең гомуми күренеше<br><br>Рәсем. 9. Фундаментның дивар яссылыгыннан чыгып торуы |

| | | |
|---|---|---|
| 5. | Конструктив схемасы: элеккегедән сакланган, кыргый бутовой таш стеналар; агач балкаларга салынган яссы такта түшәмәләр; уемнарда аркылы агач тыгылышлар; агач тәрәзә төпләре; керү юлының уң ягында сакланган таш нигезгә төзелгән, чормага алып бара торган ике маршлы агач баскыч (югалтылган); манараның урнашу урыны, конфигурациясе, габаритлары, конструкциясе, манараның һәм манараның ахырына кадәр тәмамлану материалы (югалтылган) | <br>Рәсем. 10. Бут таштан өелгән дивар<br><br>Рәсем. 11. агач балкаларга салынган яссы такта түшәмәләр<br><br>Рәсем. 12. Тәрәзә уемнарының ясалышы |

| | | |
|---|---|---|
| | | <br>Рәсем.13. Тәрәзә төбе такталары<br><br>Рәсем. 14. Баскычның таш нигезе (югалтылган) |
| 6. | Мәчетнең төп өлешен тәшкил иткән, дүрт яклы вальма түбәнең, ике яклы михраб түбәсенең һәм түбәнең югары нокталарыннан түбәнрәк урнашкан агач өйалды түбәсенең тарихи конфигурация һәм габаритлары (беренчел сыйфатта югалтылган); алты кырлы нигездә урнашкан, киселешендә күпкырлы, чатыр рәвешендә тәмамланучы (югалтылган) манараның тарихи конфигурация һәм габаритлары; түбәнең тарихи материалы: табаклы тимер. | <br>Рәсем. 16. Түбә күренеше |



Рәсем. 17.  Михрабның ике яклы түбәсе





Рәсем. 18. Чатыр төсле тәмамланган күпкырлы манараның урнашу урыны, габаритлары, конфигурациясе


| | | |
|---|---|---|
| | | <br>Рәсем. 19. Соңгы манараның агач корылмалары |
| 7. | Фасадларның композицион һәм архитектур бирелеше: биш тәрәзә күчәрендәге, диварлар яссылыгыннан чыгып торган вертикаль буынлы, почмаклы һәм стена ара пилястралы бинаның төп өлешенең көнбатыш һәм көнчыгыш фасадларының ике өлешле композициясе – намаз уку бүлмәсенең өч тәрәзә күчәре белән аерылып чыгарылган өлеше, ике тәрәзә күчәре белән аерылып чыгарылган вестибюльнең бер өлеше, көньяк диварның уртасында урнашкан, бинаның биеклеге белән тәңгәл михрабның тәрәзә белән яктыртылган ярымцилиндрлы киңлеге | <br>Рәсем 20. Көнбатыш фасад фрагменты<br><br>Рәсем 21. Тәрәзә уемнары |


Рәсем 22. Көньяктан гомуми күренеш


Рәсем. 23. Көнчыгыштан гомуми күренеш


Рәсем24. Көньяктан гомуми күренеш

| | | |
|---|---|---|
| | | <br>Рәсем. 25. Төньяк-көнбатыштан гомуми күренеш |
| 8. | Тарихи тәрәзә һәм ишек уемнарының урнашу урыны, конфигурациясе һәм пропорцияләре; тәрәзә һәм ишек уемнарының колодалы столярлык тутырылышының геометриясе һәм конструкциясе (тутырулар юкка чыккан). | <br>Рәсем. 26. Тәрәзә уемнарының пропорцияләре<br><br>Рәсем. 27. Тәрәзә уемнарының урнашу урыны |

| | | |
|---|---|---|
| | | <br>Рәсем. 28. Тәрәзә уемнарының аркылы агач такталары<br><br><br>Рәсем. 29. Тәрәзә уемнарының аркылы агач такталары |

| | | |
|---|---|---|
| | | <br>Рәсем. 30. Михраб куышы<br><br>Рәсем. 31. Мәчетнең таш күләменә караган тарихи агач ишек күренеше |

| | | |
|---|---|---|
| 9. | Фасадларның бизәлеше һәм архитектура детальләре: бинаның таш фасадлары өслеге известь сылау буенча буялган, көнбатыш һәм көнчыгыш фасадларның урта өлешендә почмакларны эшкәрткәндә һәм тәрәзә уемнарында яссы профильле пилястрлар, яссы йөзлекләр белән рамланган турыпочмаклы тәрәзә уемнары баскычлы профильле кәрниз рәвешендә тәмамланган. | <br>Рәсем. 32. Таш диварлардан чыгып торучы, конструктив бәйләнеш ясаучы агач элементлары<br><br>Рәсем 33. Көнчыгыш фасадтагы пилястралар |

| | | |
|---|---|---|
| | | <br>Рәсем. 34. Көнчыгыш фасад фрагменты<br><br>Рәсем. 35. Яссы йөзлекләр белән рамланган турыпочмаклы тәрәзә уемнары баскычлы профильле кәрниз рәвешендә тәмамланган |

| | | |
|---|---|---|
| 10 | Интерьерларның декоратив бизәлеше: штукатурланган һәм буялган шома диварлар (буяу катламнары зондаж ачулар һәм химик-технологик тикшеренүләр нәтиҗәләренә таянып билгеләнә), михрабның гипс белән рамланган аркалы куышы (югалтылган); таш баганаларга салынган агач балкалар буенча җәелгән такта идәннәр (югалтылган); агач түшәм түбә өрлекләренә салынган, таш стена ояларына ябыштырылган такталар. | <br>Рәсем. 36. Михраб куышы<br><br>Рәсем. 37. Михраб диварларының эшләнелгән катламнары |

| | | |
|---|---|---|
| | | <br>Рәсем. 38. Түбәнең агач конструкцияләре |